# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

20 март 2022 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә шушы сорау буенча 10 сәгать 00 минутта 2022 елның 20 мартында узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Сез Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы карарга (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

а) Карардагы «2000 сум күләмендә" сүзләрен «58500 сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3.3. пункты өстәргә «Гремячий Ключ авылында суүткәргеч челтәрләрен салу».

«ӘЙЕ» « КАРШЫ».

Җыенда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, халык җыенына чыгарылган мәсьәлә түбәндәгечә: «Сез Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ торак пунктында гражданнар Җыенының нәтиҗәләре турындагы карарга (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

а) Карардагы «2000 сум күләмендә" сүзләрен «31000 сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3.3. пункты өстәргә «Гремячий Ключ авылында суүткәргеч челтәрләрен салу».

«ӘЙЕ» « КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 7 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **5** кеше катнашты, бу **72 %** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **5** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. 1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ авылында халык җыены булып узды дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Сез Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ торак пунктында граждannар Җыенының нәтиҗәләре турындагы карарга (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

а) Карардагы «2000 сум күләмендә" сүзләрен «31000 сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга ;

б) 3.3. пункты өстәргә «Гремячий Ключ авылында суүткәргеч челтәрләрен салу».

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»»» соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында**
**рәислек итүче** **И.М.Фатхуллин**